ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

**20 март 2024 ел**

**№1**

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Илексаз авылы гражданнары халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Илексаз авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. "2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Илексаз авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Илексаз авылы гражданнары халык җыенын Илексаз авылы мәдәният йорты бинасында, Илексаз авылы Комсомол урамы 2 нче йорт адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 15 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Илексаз авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1. Урамнарның яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Илексаз авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар һәм материаллар сатып алу; агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту));

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Илексаз торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Илексаз торак пунктының Яшьләр урамындагы вак таш япмасын ремонтлау (вак таш ташу); күрсәткеч такталар һәм юл билгеләре, юлларны буяу өчен буяулар сатып алу Илексаз торак пунктында юл билгеләре кую);

3. Янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын (мотопомпа өчен запас частьләр, сулык өчен материаллар сатып алу; күрсәткеч такта; Илексаз торак пункты янгын сүндерү сулыгы дамбасын киңәйтү өчен туфрак ташу)төзү, ремонтлау);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Илексаз торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу; материаллар, мәгълүмат стенды, ял итү зонасы өчен баннерлар сатып алу);

5. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (материаллар сатып алу);?

“ӘЙЕ” “ЮК”?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Илексаз авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Илексаз авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Ф.М.Гыйлфанов

Совет Иляксазского сельского поселения
Илексаз авыл җирлеге Советы